ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

# КАРАР

« 19 » ноябрь 2021 ел № 1925

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында ихтыярыйлыкны (волонтерлыкны) үстерү буенча Совет төзү турында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Арча муниципаль районы территориясендә эшчәнлек алып баручы ихтыярыйлык (волонтерлык) җәмгыятен үстерү һәм иректе берләшмәләр эшчәнлегенә ярдәм итү максатларында Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында ихтыярыйлыкны (волонтерлыкны) үстерү буенча Совет булдырырга.

2. Расларга:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында ихтыярыйлыкны (волонтерлыкны) үстерү буенча Совет турында Нигезләмәне (1 нче кушымта).

2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында ихтыярыйлыкны (волонтерлыкны) үстерү буенча Совет составын (2 нче кушымта).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Э.Ш. Вафинага йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Р.Р. Мөхәрәмов

Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
19. 11. 2021 ел, №1925
карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында ихтыярыйлыкны (волонтерлыкны) үстерү буенча Совет турында**
**Нигезләмә**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1 Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында ихтыярыйлыкны (волонтерлыкны) үстерү буенча Совет (алга таба - Совет) җирле үзидарә органнарының килешенгән гамәлләрен һәм аларның ихтыярый (волонтерлык) эшчәнлеге өлкәсендәге иҗтимагый оешмалар белән хезмәттәшлеген тәэмин итү максатларында төзелгән консультатив орган булып тора.

1.2. Совет үз эшчәнлегендә федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының муниципаль норматив хокукый актларына һәм әлеге Нигезләмәгә таяна.

2. Советның максатлары һәм бурычлары

2.1. Совет эшчәнлегенең төп максаты-Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында ихтыярыйлык хәрәкәтенә (волонтерлыкка) ярдәм итү һәм аны үстерү мәсьәләләре буенча җирле үзидарә органнары һәм ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлеге субъектларының нәтиҗәле хезмәттәшлеген оештыру.

2.2. Советның төп бурычлары:

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында ихтыярыйларга (волонтерлар) ярдәм итү һәм аны үстерү мәсьәләләре буенча җирле үзидарә органнары һәм ихтыярый хәрәкәт (волонтерлык) эшчәнлеген координацияләү;
- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында ихтыярыйлык (волонтерлык) өстенлекле юнәлешләренә ярдәм итү һәм ихтыярый (волонтерлык) эшчәнлекне алып бару буенча тәкъдимнәр әзерләү;
- ихтыярый (волонтерлык) эшчәнлекнең төп юнәлешләре (мәгариф, сәламәтлек саклау, граждан-патриотик тәрбия, мәдәният, халыкка социаль

ярдәм һәм социаль хезмәт күрсәтү, әйләнә-тирә мохитне саклау, гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәләрен кисәтү һәм бетерү, әчке эшләр органнарына ярдәм итү, вакыйгаи, инклюзив, корпоратив ихтыярыйлык (волонтерлык), өлкән яшьтәге гражданнарның ихтыярый хәрәкәте (волонтерлык) - «көмеш волонтерлык») буенча ирекле (волонтерлык) эшчәнлеккә методик ярдәм күрсәтү;

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлегенә комплекслы анализ ясау.

## 3. Советның вәкаләтләре

Үз компетенциясе чикләрендә Совет түбәндәгеләргә хокуклы:

3.1. Дәүләт органнарыннан һәм җирле үзидарә органнарыннан Совет компетенциясенә кагылышлы мәсьәләләр буенча мәгълүмат һәм материаллар соратып алырга;

3.2. Совет әгъзаларының берсе җитәкчелегендә, Совет бурычларын һәм функцияләрен гамәлгә ашыруга бәйле аерым мәсьәләләрне эшләү өчен, кызыксынучы затлар җәлеп ителгән Совет әгъзалары арасыннан вакытлы һәм даими эшләүче эшче төркем төзергә.

## 4. Советның составы һәм аның эшчәнлеген оештыру

4.1. Советның составы Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана.

4.2. Совет Совет рәисе, рәис урынбасары, Совет секретаре һәм Советның башка әгъзалары составында төзелә.

Совет составында агымдагы эшне оештыру өчен эшчәнлекнең төп юнәлешләре буенча комиссияләр (эшче төркемнәр) төзелергә мөмкин.

4.3. Совет рәисе аның эшчәнлегенә җитәкчелек итә, Совет утырышларын уздыра, Совет эшенең планын раслый, Совет әгъзалары арасында аңа йөкләнгән бурычлар һәм функцияләр кысаларында бурычларны бүлә, Совет әгъзаларына тиешле йөкләмәләр бирә, беркетмәләргә һәм Советның башка документларына кул куя.

4.4. Совет рәисе булмаган очракта, аның вәкаләтләрен Совет рәисе кушуы буенча Совет рәисе урынбасары башкара.

4.5. Совет утырышлары кирәк саен, ләкин кварталга кимендә бер тапкыр уздырыла. Совет утырышында әгъзаларының гомуми санының кимендә өчтән икесе катнашканда тулы хокуклы дип санала. Совет утырышларына материаллар Совет секретаре тарафыннан Совет утырышын уздыру датасына кадәр өч көннән дә соңга калмыйча таратылырга тиеш.

4.6. Совет әгъзасы Совет утырышларында шәхсән үзе катнашырга тиеш. Утырышта катнашу мөмкин булмаган очракта, Совет әгъзасы бу турыда, булмауның сәбәпләрен күрсәтеп, Совет рәисенә хәбәр итәргә тиеш.

4.7. Совет утырышларында тикшерелә торган мәсьәләләр Совет карары белән рәсмиләштерелә, ул утырышта катнашучы гади күпчелек тавыш белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә, утырышлар беркетмә белән рәсмиләштерелә, алар Совет рәисе тарафыннан имзалана. Тавышлар саны тигез булганда, Совет рәисе яисә Совет утырышында рәислек итүче Совет рәисе урынбасары тавышы хәлиткеч була.

4.8. Совет утырышы йомгаклары буенча беркетмәләр утырышны уздырганнан соң 10 эш көне эчендә рәсмиләштерелә һәм Совет рәисе кул куйганнан соң оч көн эчендә Советның республика башкарма хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының муниципаль учреждениеләренә кызыксынучы барлык әгъзаларына җибәрелә.

4.9. Ихтыярыйлык (волонтерлык) мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр әзерләү, шулай ук халыкны тиешле өлкәдә ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлегенә җәлеп итү өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге җаваплы.

4.10. Советның үз компетенциясе нигезендә кабул ителә торган карарлары тәкъдим итү характерында.

Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
19. 11. 2021 ел, №1925
карарына 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында ихтыярыйлыкны (волонтерлыкны) үстерү буенча Совет**

**СОСТАВЫ**

Э.Ш.Вафина - Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары, Совет рәисе;

Габделгазизов И.Н. - Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгы, Совет рәисе урынбасары;

Ибраһимова Ю.Р - Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге баш белгече, Совет секретаре.

Совет әгъзалары:

1. Ильина Л.Ю.-Арча муниципаль районының «Мәгариф идарәсе» МУ җитәкчесе урынбасары
2. Әюпов И.И. - Арча районының «Мәдәният идарәсе» МУ башлыгы;
3. Шакирова М.Н. - Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Арча муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы;
4. КузмичеваР.Ю - "Арча үзәк район хастаханәсе" ДАССУ шәфкать туташы;
5. Гатауллина И.Р - "Арча үзәк район хастаханәсе" ДАССУ шәфкать туташы;
6. Мамадалеева Р.Р. - Арча муниципаль районының Арча гуманитар-техник техникумы җитәкчесе;
7. Сәләхиева Л.Ф.-Арча муниципаль районының Г.Тукай исемендәге Арча педагогика көллияте җитәкчесе урынбасары;
8. Вәлиева Л.Х. - Арча муниципаль районының Арча агросәнәгать һөнәри көллияте җитәкчесе урынбасары;
9. Миңнуллин Э.З-Арча муниципаль районы мөхтасибе;
10. Мортазина А.М. - «Җиңү волонтерлары» клубы җитәкчесе;
11. Хәкимҗанова А.Ф. - балигъ булмаганнар эшләре буенча комитет башлыгы;
12. Яруллина Р.Г. -Арча районының опека һәм попечительлек бүлеге башлыгы;
13. Лесенко А.П - Арча районы Яшьләр парламенты рәисе;
14. Әхмәдуллин К.А. - Арча районының Аграр яшьләр берләшмәсе җитәкчесе;

15.Әһлиев Р.А. - Гомумроссия халык фронты активисты һәм эксперты;
16.Миннибева Г.В - «Арча хәбәрләре» сайтының мөхәррире.